РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ГЛАВА
МАЛОБУИНКОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАТАР БУАСЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«16» май 2020 ел 2 нче номерлы

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының
«Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә
"Татар Буасы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге
чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар
уздыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлекләре чикләрен үзгәртү турында» 2020 елның 15 маендагы 3-53 номерлы Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы карары нигезендә, Татар Буасы авыл җирлегендә яшәүчеләрнең «Татар Буасы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләре турындагы проектны гавами тыңлаулар уздыру юлы белән фикер алышуда катнашуга хокукларын үтәү максатларында

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә "Татар Буасы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар уздыруны Татар Буасы авыл җирлегенең Татар Буасы авылы мәдәният йорты бинасында 2020 елның 16 июненә 11.00 сәгаткә билгеләргә.

2. Гавами тыңлауларда фикер алышына торган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2020 елның 15 июненә кадәр Татар Буасы авылы, Татар Буасы авыл җирлеге башкарма комитеты, Яшьләр урамы, 33А йорт адресы буенча кабул ителә, телефон 3-36-45.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татар Буасы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы
Татар Буасы
авыл җирлеге башлыгы Р.Ф. Йосыпов